Республика Татарстан
Совет Шарлиареминского сельского
поселения Сармановского муниципального района

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Шәрләрәмә авыл җирлеге советы

РЕШЕНИЕ

КАРАР

2016 ел, 25 январь

№ 16

Референдум үткәрү инициативасы турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 12.06.2002 ел, № 67-ФЗ Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 22, 56 ст., «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 20 ст. 1 п., Шәрләрәмә авыл җирлеге Уставының 11 ст., Сарман муниципаль районы Шәрләрәмә авыл җирлеге Советы карар иткән.:

1. Бу мәсьәлә буенча җирле референдум үткәрүне башлап җибәрергә:
"2016 елда Шәрләрәмә авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган һәр кешедән, I төркем инвалидлардан, көндезге уку йортлары студентларыннан тыш, 200 сум күләмендә үзара салым акчасын кертүегез һәм алган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерүегез белән килешәсезме?:
- каты коммуналь калдыкларны җыю һәм ташу эшчәнлеген оештыруда катнашу;
- җирлек халкының массакүләм ял итү өчен шартлар тудыру һәм халык күпләп ял итә торган урыннарны төзекләндерү;
- җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеген оештыру;
- җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне оештыру;
- җирлек территориясен төзекләндерү (урамнарны яктырту, территорияләрне яшелләндерү, кече архитектура формаларын урнаштыру һәм карап тоту); .
ЮК ӘЙЕ".
2. Әлеге карар мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерелергә тиеш.

Шәрләрәмә авыл җирлеге башлыгы: Н.Н.Хуҗина